КИЛӘЧӘККӘ ҮЙЛАП

Татарстан яшьләрен ниләр борчый?

> 2

КУРКЫНЫЧ ЧИР

Татарстандагы терлекләрдә тагын бруцеллез авыруы расланды

> 3

КАР ФАЙДАСЫ

Бата-чума, Дания апалар яшәгән йортка таба атладым...

> 3

КАДЕРЛИСЕ ИДЕ

Милли опера язучыларны каһарманнар диясе генә кала...

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 20 (29180) | Чәршәмбе | 14 февраль | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Көн кадагында

ӨЙЛӘНҮ ТҮГЕЛ СӨЙЛӘНҮ

Озак яшим дисәң, өйләнергә кирәк! Хөкүмәт йортында узган атналык брифинг бу юлы әнә шундый кызыклы фикердән башланып китте. Уйнап кына түгел, чынбарлыкны күздә тотып әйтелгән сүзләр иде бу. «Демография» илкүләм проектын тормышка ашыруга багышланган очрашу шул рәвешле Гаилә елын уздыру, ата-ана, балаларга тиешле ярдәм чаралары турында сөйләшү белән үрелеп барды.

Хәзер исәпләнми

Социаль фондның Татарстан буенча бүлеге башлыгы Эдуард Вафин сүзләренә караганда, бала үстерүче ата-аналарга ярдәм итү ил сәясәтендәге өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып кала бирә.

– Ана капиталы – «Демография» илкүләм проекты кысасында каралган төп ярдәм чараларының берсе. Быел аның күләме тагын да артты. Хәзер беренче балага – 630 мең сум, икенче балага 833 мең сум күләмендә ана капиталы түләнә. Гомумән алганда, соңгы 17 елда ана капиталы күләме өч тапкыр артты. Шул вакыт эчендә аннан Татарстанда яшәүче 408,6 мең гаилә файдаланган, – дип ачыклык кертте ул.

Гаиләләр ана капиталы акчасын нигездә әнә шул максатларга тоткан:
- **торак шартларын яхшыртуга (305 мең гаилә);**
- **балаларны укытуга (43 мең гаилә);**
- **ана капиталыннан айлык түләүгә (18 мең гаилә);**
- **пенсиянең туплама өлешен булдыруга (171 гаилә);**
- **инвалид балага кирәк-ярак алу, аңа күрсәтелгән хезмәтләр өчен (2 гариза).**

Сүз уңаеннан, быел ана капиталыннан файдалану шартларына кайбер үзгәрешләр дә кертелде. Беренчедән, дәүләт тарафыннан каралган әлеге ярдәмнән бала туган чорда Россия гражданлыгына ия булган ата-ана гына файдалана ала. Баласын үзе генә үстергән һәм ана капиталы алырга хокукы булган ялгыз аталар бу акчаны пенсияләренең туплама өлешен булдыру өчен дә тота ала. Моннан тыш, быелдан башлап ана капиталы акчаларын күрше йортка тоташтырып салынган йортны тәэкләндерү өчен тотарга да рөхсәт итәчәкләр. Эдуард Вафин бу урында шуны сизын да искәртте:

Илдар Мөхәммәтҗанов

> Балаларга бердәм пособие түләүгә кагылышлы яңалыклар да бар. Быелдан башлап бала пособие алырга тиешме-юкмы икәнне ачыклаганда, «Герой ана» исеменә, «Ата-ана даны» медаленә лаек булган аналарга бирелгән түләүләр, 18 яше тулмаган балага банкта ачылган счеттагы процент акчалары, үсмер баланың укудан тыш эшләп алган акчалары исәпкә алынмаячак. Баланың атасы мобилизациягә эләгеп, махсус хәрби операциягә киткән икән, балага пособие билгеләгәндә әтисенең моңа кадәр алган керемнәре шулай ук исәпләнми.

Татарстан хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Наталья Бутаева белдерүенчә, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына балалар бакчасына йөргәндә, мәктәпкә укырга кергәндә өстенлек бирелә. Алар көллияткә, вузга укырга кергәндә, балалар сәламәтләндерү үзәкләренә барганда да чиратсыз үткәрелә.

– Татарстан Хөкүмәте карары белән махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары билгеләнде. Мобилизациягә эләккән ирләрнең 18 яшькәчә балаларына бер тапкыр 20 мең сум акча түләнә, – дип ачыклык кертте министр урынбасары.

Табарга ашыкмыйлар

Татарстан Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы Гөлшат Нигъмәтуллина гаилә корырга илһамландыручы тагын бер сәбәпне атады. Баксаң, өйләнгән ир-атлар буйдакларга караганда озаграк яши икән.

– Статистикадан күренгәнчә, буйдаклар кыскарак гомерле була. Алар хроник чирләргә дә, стресска да тизрәк бирешә. Шуңа күрә өйләнмичә йөргән ир-атларга бу мөмкинлектән файдаланырга, гаилә корып, тагын да бәхетлерәк яшәргә киңәш итәр идем, – диде идарә башлыгы, уенын-чынын бергә кушып.

Ахыры 2 нче биттә >

Тизрәк түли башлыйлар

Россия Президенты Владимир Путин махсус хәрби операциядә катнашучыларга ташламалар һәм түләүләрне тизләтү буенча тәкъдимнәр әзерләргә кушкан. Дәүләт башлыгының зур матбугат конференциясе йомгаклары буенча әзерләнгән бурычлар исемлегеннән шуны күрергә мөмкин.

Әлеге бурыч Россия Хөкүмәтенә йөкләнгән. Аны үтәүгә җаваплы итеп Премьер-министр Михаил Мишустин билгеләнгән.

Исегезгә төшерәбез: Президентка матбугат конференциясе барышында махсус хәрби операциядә катнашучыларга түләүне яхшырту үтенече белән мөрәҗәгать иттеләр. Аерым алганда, кайбер хәрбиләрнең айлар буе акча алмаганлыгы турында әйтелде.

Үз куышың

Быел Татарстанда ким дигәндә 3 миллион 150 мең кв. метр торак төзеп тапшыру күздә тотыла. Бу хакта төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин әйтте. Планның 13 проценты үтәлгән инде. Коммерция юнәлешендә – 68,9 мең (22 йорт), социаль ипотека программасы буенча – 29 мең (12 йорт), шәхси төзелештә 301 мең кв. метр (2229 йорт) торак тапшырылган.

Татарстанда быел 930 ятим баланы торaклы итәргә җыеналар. Алар өчен 1 млрд 742 млн сум күләмендә акча каралган. Торак алучылар арасында биш һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче 28 гаилә дә булачак. Моннан тыш, быел 84 яшь гаиләне дә сөендерергә җыеналар.

Йомырка арзаная

Ел башыннан бирле илдә йомырка бәясе 3 процентка очсызланган. Татарстанда узган атнада гына ул 71 тиенгә арзанайган. Бүген кибетләрдә ун йомырка уртача 126 сум тора.

Татарстанстаттан алынган мәгълүматларга караганда, узган атнада республикада яшелчә бәяләре кыйммәтләнгән. Барыннан да бигрәк кызыл чөгендер уздырган. Аның бер килосы 6 процентка кыйммәтләнеп, 35 сумлык чикне узып киткән. Кәбестә, якынча 5,5 процентка кыйммәтләнеп, уртача 33 сумга җиткән. Кыярның бер килосы якынча 234 сумнан 240 сумга кадәр (2,8 процентка артып) җиткән. Иң нык кыйммәтләнгән яшелчәләр арасында суган һәм бәрәңге дә бар. Аның каравы помидор 1,8 процентка очсызланган. Хәзер аның бер килосы уртача 235 сум тора.

Һава хәле

Кирәкле кыш

Суыта! Синоптиклар шулай дип кисәтә. Бу атна ахырында республикада термометр баганасы –33 градуска кадәр төшәчәк. Аның каравы буран тынды. Татарстанда февральдә айлык норманың 95 проценты кадәр кар яуган инде. Быелгы кышка сатучылар гына сөенә. Гыйнварда кирәк 57 процентка күбрәк сатылган әнә. Ә чиратта – резин итек...

Быелгы кыш йә бураннары, йә суыклары белән сынавын дәвам иттерә. Урамнарны, йорт тирәләрен баскан кар көртләреннән бераз арындык дип җиңел сулап куярга да өлгермәдек, Татарстанга суыклар килде. Синоптиклар сүзенә ышансаң, атна азагында республиканың кайбер районнарында төнлә –33 градуска кадәр суытачак. Кар-буран кичәтмәли.

Хәер, быелгы карның яуган кадәре дә бик җиткән. Казан мэры Илсур Метшин соңгы өч атнада дулаган буранны табигать бәла-казасы дип атады. Гыйнварда башкалада айлык норманың 170 проценты кадәр кар яуса, февральдә әлеге сан 95не тәшкил иткән инде. Әле бит айның яртысын гына вакладык. Урамнарны кардан чистартып та бетерә алмыйлар. Шәһәр мәриясе мәгълүматларына караганда, карны җыештырырга көн саен 1 меңләп техника һәм 750 эшче чыга. Кар эретү станцияләренә һәм аны вакытлыча саклау урыннарына көн саен 30 мең тонна кар ташыйлар.

Тик бу эшнең дә җае бар. «Карны элеккеге кебек юл тирәсендәге чокыр-чакырларга бушатырга ярамый. Алай итү табигатькә саклау законнары бозу булып санала», – дип, мәсьәләгә ачыклык кертkән Илсур Метшин. Ул быелгы кар көртләренә каршы көрәштә гади халыктан ярдәм дә сораган.

– Бу – табигать бәла-казасы. Йорт янганда күршеләр: «Янгын сүндерүчеләр ушкеп, бу – аларның эше», – дип читтән генә күзәтеп тормый бит. Бөтен дөнья белән булышалар, – дигән ул.

Казанның «Матур» бистәсендә яшәүче Мансур Гарипов ярдәм килгәнне көтеп тормаган. Ул үзенә кар эретү җайланмасы сатып алган.

– Безнең урам бик тар. Карны чыгарырга урын калмады. Шуңа күрә 40 мең сумга кар эретү җайланмасы сатып алдым. Ул электр ярдәмендә эшли, утны күп «ашамый». Ишегалдындагы карны өч-дүрт сәгатьтә эретеп бетерә. Саный китсәң, урамнан кар чыгарырга дип бер тапкыр «КамАЗ» чакыртkан өчен дә 10–12 мең сум түләргә кирәк. Киләсе елга да кыш шундый карлы булса, эреткеч үзен үзе аклаячак, – ди Мансур Гарипов.

Кибетләрдә кирәк сатып алучылар да бермә-бер арткан. Маркетплейсларның берсе хәбәр итүенчә, узган елның гыйнвары белән чагыштырганда, быел көрәккә заказ бирүчеләр 57 процентка күбрәк. Алдан аяк киенүчеләр дә җитәрлек: кибетләрдә резин итекләргә сорау арткан, ди. Карлы кыштан соң килгән яздан ни көтәсе билгеле.

Теманың дәвамы 3 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Никита ЧАПЛИН, Дәүләт Думасының бюджет һәм салымнар буенча комитеты әгъзасы:

Кайберәүләр, үзмәшгульләргә беркөнне кинәт кенә салымны күтәреп куярлар, дип курка торганнардыр. Бу алай түгел. Закон буенча, 2028 елның 31 декабренә кадәр Россиядә эксперимент кертелгән: аның нигезендә үзмәшгульләрнең салым ставкасын күтәрергә ярамый.

«Парламентская газета»дан

РОССИЯДӘ – ГАИЛӘ БЮДЖЕТЫ

Гаиләдә акча кем кулында? Superjob аналитиклары шуны белешкән. Баксаң, 2020 елда гражданнарның 5 проценты гаилә бюджетын аерым алып баруны дөрес дип санаган, 2022 елда инде 9 проценты шундый фикердә булган.



Безнекеләрдә – алтын

Татарстан җыелма командасы Иң көчлеләр спартакиадасында ир-егетләр арасында узган чаңгы эстафетасында беренче урынны алды. Республика данын Андрей Ларьков, Сергей Ардашев, Антон Тимашов һәм Иван Горбунов яклады. Безнең спортчылар соңгы этапны 16,2 секунда калышып, икенче урында башласа да, Иван Горбунов финишка беренче булып килә алды. Ярышта икенче урынны Коми чаңгычылары алды. Өченче урында – Төмән командасы. Хатын-кыз чаңгычылары арасында узган ярышта исә Татарстан спортчылары өченче урынны алды. Финишка беренче булып Архангельск өлкәсе командасы килде.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТОРАК БАЗАРЫ ҖИМЕРЕЛГӘНДӘ

Глобаль кризис үзенең традицион схемасын кабатлый башлады. Бу күптән көтелә иде инде. Без «Ватаным Татарстан»да бу хакта бер генә тапкыр язмадык. Соңгы елларның түнтәрелеше һәрвакыттагы да торак төзелеше ягыннан килә, чөнки иң яхшы инвестиция чарасы булып фатирлар санала: ихтыяҗ зур, бәяләр үсә. Банклар, шуңа кызыгып, төзелеш компанияләренең акцияләрен сатып ала. Бәяләр һәрвакыт болытларга килеп терәлә дә, кешеләр андый бәягә торак алудан туктый.

Моны хәле начарайган банклар тиз сизеп ала һәм кыйммәт чагында девелопер (зуррак табышка өметләнеп, яңа күчемсез объектлар төзүгә акча кертүче. – **Ред.**) компанияләрнең акцияләрен сатарга керешә. Русча әйтсәк, распродажа башлана. Распродажа вакытында бәяләр төшә. Банкирлар, паникага бирелеп, очсызланган кәгазьләрдән тизрәк котылырга тели. Бугенге сатып калмасаң, иртәгә чүп бәясенә сатасың. Базардагы ыгы-зыгыны күреп, депозит ияләре дә тик ятмый, банкка салган акчаларын кире таләп итәләр. Шулай итеп, банк акцияләре дә түбәнгә оча. Кыйммәтле кәгазьләрнең бәясе номиналдан түбәнәйгәч, банк дефолт игълан итми кала алмый, чөнки ликвидлык дигән нәрсә бетә. Кертем ияләренә акчаларын кайтарып бирә алмагач, нишләтсеннәр?

Үткән ел Америкада һәм Европада банк кризисы башланган иде инде. Ул чакта проблемалы эре банклар бөлгән банкларны сатып алып хәл иттеләр. Хәзер проблемалы активларны алган банклар чираты җитте. New York Community Bank шундыйларның берсе иде. Финанс аналитиклары ачсагыз, аның турында: «...ипотека активларын сату хакында сөйләшүләр алып бара. Ел башыннан аның акцияләре 65 процентка очсызланды инде. Банк ликвидлыкны яхшырту һәм ипотека портфелен сату өчен инвесторлар эзли», – дигән хәбәргә юлыгырсыз.

Эшнең кая таба барганын сизәсеме? Инвесторлар табылачакмы? Табылса да, пүчтәк бәягә генә сатып алачаклар. Кризис инде Европа банкларына килеп сукты. Яңалыклардан без: «Дефолт хәвефе Европа банкларына тарала. Немец банкы PBB акцияләре кучемсез милек проблемалары фонында түбәнәя. Алар бер ай эчендә 25 процентка очсызланды», – дигән хәбәр укый алабыз. Бурычка алган акчаның 25 проценттын суга ташласагыз, әҗәтегезне ничек түлисез? Менә шул шул. Ләкин очсызлану дәвам итә.

Кризис бу юлы Америкадан да, Европадан да, Япониядән дә башланмады. Давыл Кытайдан исә. Бу илнең төзелеш компанияләре барысы да дефолт хәлендә һәм алар, бурычларын каплау өчен, чит илдәге активларын сата башлады. Үзләренекен сата алмыйлар, чөнки бәяләр секунд эчендә чүпкә калачак. Көнбатыштан бераз каерып була әле, вакытында сатып калырга гына кирәк. Теманы тагын да шәрехли алмыйбыз, чөнки урын бетте. Яңалыкларны күзәтеп барыгыз, безне гаҗәеп хәлләр көтә.

Россиядә

ТОРАК ТҮГЕЛ, МӨҺАҖИРЛӘР ҺӘМ СӨТ КРИЗИСЫ

Россиянең глобаль финанс базарыннан өзелүе безне әлегә күчемсез милек һәм банк тармагындагы тетрәнүләрдән саклый. Бездәге банклар кулында чит ил төзелеш компанияләре акцияләре бар микән? Булса да, алар чикнең тегеягындагы паникага кушыла алмый, чөнки, бердән, ул базарларда безнекеләрне биетмиләр, икенчедән, Россия банклары югалтырдай чит ил активларын югалтып бетерде инде.

Ипотека кредиты бирү эчке базарда нык чикләнде. Үзәк банк Көнбатыш һәм Кытайдагы кризистан шулай саклангыга тырыша. Гыйнвар ипотекасы декабрьнекеннән 66 процентка ким. Бик зур сан бу. Үзе генә дә кризис китереп чыгара алыр иде. Чынлап та, гыйнвар аенда Мәскәү төбәгендә яңа төзелгән торак сату 52 процентка кимегән. Беренче карашка чыпчын кризис. Әмма квадрат метр бәясе аз гына да төшмәгән: уртача 306,1 мең сум калган. Кризис булсын өчен, бу бәянең дә ишелүе кирәк. Россиянең төп үзенчәлеге шунда: хөкүмәт бәяләрне төшерми тотып тору осталыгына ия. Банклар да кризистан акция сатып котылмый: бюджеттан мул итеп ярдәм акчаға гына коена. Менә хәзер дә хөкүмәтнең төзелеш блогы Үзәк банк белән өстенлекле ипотеканы озынайту өчен тартыша. Шуңа күрә без, казнада акча беткәнче, үзебезне кризистан имин тоябыз.

Россиягә проблемалар башка яктан яный. Эшче куллар җитми, ә мөһаҗирләрне тартып китерү кыенлаша. Дөнья базарында мигрантлар өчен чып-чын тартыш бара. Кытайда да, Көнбатышта да демографик кризис көчәйгәннән-көчәя. Халыклар картая һәм яшь көчләрне импортлау ихтыяҗы барлыкка килә. Урта Азиядәгеләрне, мәсәлән, Кытай үзенә җәлеп итә башлаган. Бай гарәп илләре дә бу тартышка кушылган. Үзбәкләр Европага кыяклау җаен күбрәк карыйлар икән. Россия мөһаҗирләре торган саен азрак кызыксындыра. Сумның тотрыксызлыгы моңа үз өлешен кертә. Элек мөһаҗир ай саен үз иленә уртача 300 доллар күчергән, хәзер 200не генә. Җитмәсә, банк аша акча күчерү чып-чын газапка әйләнеп бара. Ай саен кесәгә кагазь акча тутырып, туган илгә чаба алмыйсың.

Тагын бер кризис, йомырка кризисы урынына сөт кризисы өлгереп килә, диләр. Көтеп карыйк: сөткә бәя сикерерме, юкмы?

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ЭШЛӘГӘН ТУҢМАС

tatarstan.ru

42 мең йөк машинасы, 68 мең сум хезмәт хакы һәм 100 баллы укучылар. Чаллы шәһәр советы утырышында узган елга йомгак ясадылар. Анда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Утырышка кадәр Рөстәм Миңнеханов Чаллы сәнәгать предприятиеләре һәм социаль тармагы күргәзмәсе белән танышты. Былтыр ирешкән төп уңышлар турында сессиядә шәһәр мэры Наил Мәһдиев җиткерде. 2023 елда автокалада 737 миллиард сумлык товар тәэп озаткканнар. КАМАЗда гына да 42 меңгә якын йөк машинасы җитештергәннәр. Шәһәргә ел дәвамында 77 миллиард сумлык инвестицияләр җәлеп ителгән. Былтыр Чаллыда 318 мең квадрат метр торак кулланышка тапшырылган. Быел әлеге санны 320 мең квадрат метрга җиткерергә ниятлиләр. Наил Мәһдиев мәгариф өлкәсендәге уңышларга да аерым тукталды. Былтыр бирәдә мәктәп бетергән һәр дүртенче укучы 80–100 балл җыйган. Шулар арасыннан 27 чыгарылыш сыйныф укучысы – иң зур балл ияләре.

Наил Мәһдиев махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм чаралары турында да әйтте. Шәһәрдә әлеге мәсьәләгә зур игътибар бирәләр. Аерым алганда, махсус хәрби операция зонасындагы хәрбиләрнең яңа туган балаларына 100әр мең сум күләмендә акча түләнә.

Бу эшнең әһәмиятен Рөстәм Миңнеханов та ассызыклады. Аның әйтүенчә, яу кырында һәлак булган солдатларның якыннары һәм туганнары аеруча да безнең ярдәмгә мохтаҗ. Бу уңайдан, Чаллыда эш югары дәрәҗәдә оештырылган, дип билгеләп үтте Татарстан Рәисе.

Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, Чаллы республика гына түгел, ил күләмендә тисациясында сәнәгать үзәге. Беренчелек КАМАЗда, әлбәттә. Шәһәрдә җитештерелгән сәнәгать продукциясенең 43 проценты нәкъ менә автогигантка туры килә. Зур предприятиеләр белән берлектә, Чаллыда кече һәм урта бизнес та уңышлы үсеш алган, диде Рөстәм Миңнеханов. Мәсәлән, «Чаллы» алгарышлы үсеш территориясе ил күләмендә иң яхшыларының берсе булып санала.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, сәнәгатьнең тотрыклы үсеше өчен тармакның өстәмә эшче көчләр белән тәэмин итәргә дә кирәк. «Бу эштә безгә мигрантлардан башка булмый», – диде Татарстан Рәисе. Эш бирүчеләргә бу мәсьәләдә игътибарлырак булырга да киңәш итте ул.

Татарстанда, шул исәптән Чаллыда тормышка ашырылучы илкүләм һәм республика проектлары турында сөйләгәндә, Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узу юлы төзелеше турында да искә алдылар. Билгеле булганча, бирәдә Чулман елгасы аша күпер дә салына.

– Әлеге проектны тормышка ашыру барышы өчен дә зур бүләк булачак, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Республика башлыгы алда торган төп бурычларның берсе – халыкның тормыш сыйфатын яхшырту турында да искә төшерде.

– Хезмәт хакы буенча Чаллы республика күләмендәге уртача күрсәткечне уздыра. Бирәдә яшәүчеләр уртача 68 мең сум акча ала. Шул ук вакытта шәһәр халкының барысы да мондый мөмкинлеккә ия түгел: Чаллыда яшәүче 25 мең кешенең айлык кереме яшәү минимумыннан да түбәнрәк. Узган елның өченче чиреге нәтиҗәләренә караганда, 51 предприятие үз хезмәткәрләренә минимальь хезмәт хакы күрсәткеченнән дә азрак акча түләгән. Шәһәр мәриясе эш бирүчеләр белән берлектә хезмәт хакларын күтәрү һәм халыкның хезмәткә бәйле хокукларын үтәү юнәлешендә даими эшләргә тиеш, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Чаллыда Рөстәм Миңнеханов шәһәргә ун пассажир автобусы тапшыру тантанасында да катнашты. Яңа «НефАЗ»ларны федераль үзәк ярдәме белән сатып алганнар. «Кызганыч, соңгы елларда республикада транспорт белән тәэмин итү һәм пассажирларга хезмәт күрсәтү мәсьәләсенә бәйле сораулар артты. Без, федераль үзәк катнашында, зур җитди программа башладык. Ул автобусларга бәйле вазгыятьне яхшы якка үзгәртергә булышты», – диде Татарстан Рәисе. Ел азагына кадәр Чаллыда гына да 90 яңа автобус юлга чыгачак дип көтелә.

Өйләнү түгел сөйләнү

<Ахыры. Башы 1 нче биттә

Узган ел Татарстанда барлыгы 25,2 мең яңа гаилә теркәлгән. Әлеге күрсәткеч буенча республика Идел буе төбәкләре арасында беренче урында тора. Шулай да сөенергә иртәрәк. Ник дигәндә, 2022 елда республикада күбрәк – барлыгы 27,4 мең гаилә теркәлгән булган.

Гөлшат Нигъмәтуллина сүзләренә караганда, узган ел республикада 36 мең бала туган. Соңгы елларда Татарстанда беренче баласын соңарып кына алып кайтучылар саны арта бара икән. Әйтик, узган ел беренче баласын алып кайтканнарның нибары 19 проценты гына 25 яшькә кадәр тәүге тапкыр әти-әни булган. ЗАГС идарәсе башлыгы, сүз уңаеннан, быел туй гөрләтү өчен матур даталарны да атады. Белгечләр быел 17 март, 4 апрель һәм 30 август көннәрендә өйләнешүчеләр күп булыр, дип көтәләр.

Белгечләр, Гаилә елында гаиләләрнең саулыгына да игътибар артачак, дип вәгъдә итә. Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков сүзләренә караганда, өлкәннәрнең, бигрәк тә ата-аналарның сәламәтлеге аеруча игътибар үзәгендә булачак.

– Ата-ана сау-сәламәт булса, бала да сәламәт булачак. Күп кенә программаларыбыз әнә шул максатны күздә тота да инде. Быелдан башлап диспансеризация барышында халыкның репродуктив сәламәтлеген дә тикшерәчәкләр. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән узган елның мартыннан республикада «Сәнәгать диспансеризациясе» дигән проект тормышка ашырыла башлады. Шул рәвешле мондый оешмаларда эшләүчеләргә хәзер диспансеризация узу өчен дәвалау оешмасына барып торасы юк. Медицина хезмәткәрләре эш урынына үзләре килеп тикшерә. Шул рәвешле бер ел эчендә республиканың 681 оешмасында эшләүче 113 мең кеше эш урынында диспансеризация узган, – ди Владимир Жаворонков.

Министр урынбасары соңгы арада телдән төшмәгән абортлар мәсьәләсенә дә тукталды. Билгеле булганча, ел башыннан Казанда Республика кризис үзәге ачылды. Ул, иң беренче чиратта, бала төшерү очракларын кисәтүне күздә тота. Моннан тыш бирегә йөккә уза алмыйча азапланган хатын-кызлар да мөрәҗәгать итә ала.

– Абортларны тыябыз дигән сүз юк. Бу – хатын-кызның үз ихтыярында. Безнең төп бурыч – аның өчен зур йөк кебек тоелган мәсьәләне чишү юллары барлыгын күрсәтү, аңа тиешле ярдәм чаралары турында сөйләү һәм, кулдан килгәнчә, аны бу карарыннан кире кайтарырга тырышу , – ди Жаворонков.

ҮЗЛӘРЕ ГЕНӘ БЕЛӘ

Бүгенге яшьләр – нинди алар? Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгының ел нәтиҗәләренә багышланган коллегия утырышы әнә шул сорауга җавап эзләүдән башланды.

Юкка гына түгел. Яшьләргә нәрсә җитми? Тагын ничек ярдәм итәргә? Бу һәм башка сорауларга яшьләр үзләре генә җавап бирә ала. Ә ул җаваплар республикадагы яшьләр сәясәтенең киләчәккә (2030 елга кадәр) өстенлекле бурычларын билгеләргә ярдәм итәчәк. Татарстанның яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков, бу максатка ирешү өчен, быел зур социологик тикшерү уздырачакларын әйтте.

Коллегиядә яңгыраган тагын бернечә әһәмиятле сорауга тукталыйк.

Яшьләрне район, авылларда калдырыр өчен нишли алабыз? Яңалык булмаса да, министрның тәкъдимнәре болайрак яңгырый. Беренчедән, яшьләргә торак алырга ярдәм итәргә кирәк. Дөресен генә әйткәндә, авылларда гына түгел, шәһәрләрдә яшәүче яшьләр өчен дә актуаль проблема бу. Ринат Садыйков торак мәсьәләсендә парламент рәисеннән ярдәм дә сорады.

Икенчедән, эш урыннары булдырырга кирәк. Коллегиядә бу мәсьәлә бер яклы гына каралды. Министр күбрәк эшмәкәр яшьләргә, үз проектларын тәкъдим итүчеләргә ярдәм турында сөйләде, грант алырга бер мәртәбә дә гариза бирмәгән районнарга (Кайбыч һәм Актаныш) шелтә белдерде. «Исегезгә төшерәбез: грантлар яшьләр өчен файдалы булган проектларга өстәмә 4–5 млн сумга кадәр акча алырга мөмкинлек бирә», – диде ул.

Балигълык яшенә җитмәгәннәр арасындагы җинаять очраклары ничек киметергә? Узган ел Татарстанда 18е тулмаган яшьләр төрле дәрәҗәдәге 561 җинаять кылган. Министр бу куренешкә каршы көрәшне эш белән алып барырга тәкъдим итте. Чөнки күпчелек җинаятьләр, артык гади итеп әйткәндә, эшсезлектән тилмерүчеләр тарафыннан кылынган. «Әйтик, каникуллар вакытында үсмерләр «Безнең ишегалды», «Парклар һәм скверлар» программасына кергән объектларны төзекләндерүдә катнаша ала», – диде ул.

Татарстан халыкларының яшьләр ассамблеясында яңа рәис сайладылар. Бу вазыйфаны Мария Стукалова башкарачак. Элеккеге җитәкче Тимур Кадыйров хәзер Татарстан Халыклар дуслыгы йорты директоры булып эшли. Иҗтимагый оешманың хисап-сайлау конференциясендә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты. Республика парламенты башлыгы яшьләр ассамблеясының эшчәнлеген мактап телгә алды. «Сез бәяләп бетергесез эш башкарасыз», – диде ул һәм яшьләр белән эшләүне республика һәм илнең киләчәгенә кагылышлы эш дип атады. Фәрит Мөхәммәтшин яшьләр ассамблеясыннан күбрәк тәкъдимнәр көткәннәрен әйтте, районнарга ешрак чыгып йөрергә, милли диаспоралар белән күбрәк аралашырга киңәш бирде.

Яшьләрдә патриотик рухны ничек тәрбияләргә? Хәзерге вакытта Татарстанның барлык районнарында да 14 меңнән артык үсмерне берләштерүче 174 хәрби-патриотик клуб эшли. Әмма Ринат Садыйков бу җәһәттән медиакилнлеккә һәм андагы геройларга да йөз белән борылырга кирәк дип саный. Моның өчен, беренчедән, яшьләр медиаүзәге оештырылган. Хәзер инде антигеройларга алмашка үзебезнең чын каһарманнарны күрсәтә башларга кирәк. «Моның өчен «Татмедиа» агентлыгы белән бергә системалы рәвештә массакүләм мәгълүмат чараларында һәм социаль челтәрләрдә безнең заман геройларына багышланган сәхифәләр чыгарачакбыз. Яшь укытучылар, табибләр, хәрбиләр, яшь чакта зур уңышларга ирешкән эшмәкәрләр – мондый мисаллар бездә җитәрлек», – диде Ринат Садыйков.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сан

- 2023 елда **39** яшьләр объекты төзелгән һәм яңартылган, моның өчен **877 млн** сум акча тотылган. Быел бу максатларга **793 млн** сум бүленгән.
- Узган ел югары уку йортлары, иҗтимагый оешмалар һәм республика яшьләре барлыгы **163 млн** сумлык грантлар откан.
- 2023 елда **431** гаилә төрле программалар кысасында торакны булган. Чиратта торучы гаиләләрнең саны – **3152**.

Безнең яшьләр – нинди алар? Яшьләргә бәяне яшьләр үзләре генә түгел (коллегия башланганчы, «Бүгенге яшьләр – нинди алар?» соравына җавап биргән видеоролик күрсәтелде), Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да бирде. «Республика җитәкчелеге өчен яшьләр сәясәте – мөһим юнәлешләрнең берсе. Чөнки яшьләр – республиканың киләчәге. Безнең киләчәк яшьләргә бирелгән тәрбиядән тора. Бүген яшьләрнең белемле генә түгел, бик тәрбияле булуын күп нәрсә расслый. Ә иң мөһиме – безнең яшьләр патриотик яктан тәрбияле», – диде ул.

Парламент җитәкчесе дә авыл яшьләренә аерым тукталды. «Күреп торасыз: авыллар картая. Безнең өчен авыл кешесе бик зур кыйммәткә ия. Ул бит безне ашатучы гына түгел. Авылларда яшәүчеләр телне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне – милли рухны саклый. Бу – безнең байлык. Моны яшьләр дә аңларга тиеш», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

АВЫЛ ХАЛКЫ: «БАРЫБЫЗ ДА КУРКУДА»

КАЙБЫЧ РАЙОНЫНДА БРУЦЕЛЛЕЗ АВЫРУЫ АЧЫКЛАНДЫ

Татарстандагы терлекләрдә тагын бруцеллез авыруы расланды. Бу юлы авыру Кайбыч районының Иске Чәчкап авылындагы малларга зыян салган. Узган елгы ике очрактан аермалы буларак, монысында куркыныч авыру шәхси хуҗалыклардагы малларны аямаган. Алардан тыш, Айрат Пукачев фермер хуҗалыгындагы бозауларның да авыру йоктырганы ачыкланды.

«Татар-информ»

Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Габделхак Мотыйгуллин сүзләренчә, авыру биш шәхси хуҗалыкта һәм фермер хуҗалыгында чыккан.

– Фермер хуҗалыгындагы 51 баш терлекне һәм авыру чыккан шәхси хуҗалыкларның барлык малларын Кайбычтагы сугым цехында чалып, итен эшкәртеп, колбаса ясаячаклар. Безгә хәзер беренче чиратта әлеге хуҗалыклардагы малларны бетерү, дезинфекцияләү, чистарту кирәк. Авыруны таратмау – иң төп бурыч. Бруцеллезның кешеләргә йогу куркынычы да булгач, аларны да тикшерәчәкләр, – диде ул.

Без авыл халкы белән дә аралаштык. Алар әйтүенчә, бер атна эчендә өч хуҗалыкта сыерлар бозау «салгач», кешеләрнең күңеленә шик керә. Шунысын әйтергә кирәк: хуҗалыклар күршеләр түгел, ләкин бер урамда урнашканнар.

– Ике сыер бозавын төшергәч, ветеринарга хәбәр иттек. Хафага бирелмәсә дә, бу хәл контрольгә алынды. Ә инде өченче сыер да бозавын салгач, үлгән маллардан анализ алдылар. Кызганыч, авыру расланды. Шуннан соң Апастан ветеринарлар килеп, һәр хуҗалыктагы сыерлардан кан алдылар. Аларның нәтиҗәләре тагын ике хуҗалыктагы терлекләрдә шушы авыру барлыгын күрсәтте, – диде безгә исем-фамилиясен газетада күрсәтергә теләмәгән авыл кешесе.

Гадәттә, бруцеллез читтән алып кайткан маллар белән ияреп кайтырга мөмкин, диләр. Тик авыру чыккан шәхси хуҗалыкларда соңгы берничә айда терлекләр сатып алынмаган. Җәен әлеге урамның сыерлары фермерныкылар белән бергә көтүгә йөргән булган. Моннан тыш, халык сыерларын аның үгезе янына алып барган. Шуңа күрә авыру аннан күчмәдеме икән, дип тә шикләнәләр.

– Авыру малларны дүшәмбе алып китеп юк иттеләр. Шәхси хуҗалыкларның алты терлеген, фермерның бер үгезен алып киттеләр. Авыл башында кергән-чыккан машиналарны тикшереп торалар. Продукцияне кертү-чыгару тыелды, – диде әңгәмәдәшебез.

Габделхак Мотыйгуллин әйтүенчә, фермер яшерен юллар белән терлек алып кайткан булырга мөмкин. Ә шәхси хуҗалыкларга анда эшли торган кешеләр белән ияреп кайтуы да бар.

Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары халыкны иң нык борчыган сорауга исә болай дип җавап бирде:

– Иске Чәчкап авылы Кайбыч җирлегенә керә. Андагы башка терлекләргә һәм калган өч авылдагы сәламәт малларга тимибез. Язын кан алганда әлеге авыллар беренче чиратта тикшереләчәк, контрольдә булачак, – диде җитәкче. – Мин дүшәмбе үзем дә авылда эшләдем. Кешеләр бик борчулы инде. Күпчелеге үзләре өчен дип кенә бер сыер асрый. Шунысы сөендерә: малларын иминиятләштергән булганнар. Алар акчасын алачак. Моннан тыш, район башлыгы Альберт Рәхмәтуллин карары белән һәр баш өчен 50шәр мең сум акча түләячәкләр.

Иске Чәчкап авылында карантин игълан ителгән. Утыз көн дәвамында барлык терлекләр дә күзәтү астында булачак. Бруцеллез табылган очракта, аларны да юк итәргә туры киләчәк.

– Барыбыз да куркуда, беркемнең дә кәефе юк. Авыру башка малларда чыкмасын да калганнарына таралмасын иде, дип телибез. Бруцеллез килеп чыккан кешеләрнең сыерлары, сарыклары, бозаулары да бар бит әле. Авылда мал бик кадерле. Итен, сөтен бирүче, күпмедер дәрәҗәдә керем чыганагы да бит ул, – ди авылда яшәүчеләр.

Исегезгә төшерәбез: республикада күптән булып, инде онытыла төшкән авыру узган елның августында кабаттан баш калкытты. Башта Яңа Чишмә фермеры Николай Скоков хуҗалыгында бруцеллез чыгып, 700 баштан артык терлеге әрәм булды. Ел ахырында Әтнә районының «Тукай» хуҗалыгы зыян күрде. Андагы 5,5 мең баш мал юк ителде.

Бруцеллез – терлекләр һәм кешеләр өчен куркыныч булган йогышлы авыру. Маллар арасында аеруча сарыклар, кәҗәләр, мөгезле эре терлек һәм дуңгызлар авыруга нәзберек. Белгечләр әйтүенчә, бруцелла бактериясе азык, су һәм һава аша күчәргә сәләтле. Күп очракта авыруның билгеләре юк. Ләкин хуҗалыкта сыерлар бер-бер артлы бозауларын югалта башлый икән, кичекмәстән анализ тапшырырга кирәк. Әлеге авыру терлек янында булган яки аның итен пешеп бетмичә, сөтен кайнатып чыгармыйча кулланган очракта кешегә дә йогарга мөмкин. Кешеләрдә авыруның иң төп билгеләре – буыннар авырту, җенес әгъзалары ялкынсыну.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Өйрәнгәне үзе өчен

Осталык

6000 катнашучы, 302 юнәлеш, 150 мең сум күләмендә премия. Республикада һөнәри осталык буенча Бөтенроссия «Профессионаллар» чемпионатының төбәк этаплары башланды. «WorldSkills»ны алыштырган яңа чемпионат нәрсәсе белән үзенчәлекле һәм катнашучыларны ниләр көтә?

mon.tatarstan.ru

– Яңа хәрәкәтнең максаты – икътисадның төрле тармакларын кадрлар белән тәэмин итү. Төп яңалык – катнашучыларны эшкә урнаштыру мәсьәләләре буенча предприятиеләр һәм мәгариф системасының бергә хезмәттәшлек итүе, – ди Татарстан мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Андрей Поминов. – Чемпионат хәрәкәтенә ил җитәкчелеге тарафыннан зур игътибар бирелә. Икътисад секторын кадрлар белән тәэмин итү базасын булдыру өчен барысы да эшләнә. Шушы көннәрдә Президент Владимир Путин җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән остазларның да тырышлыгын күрергә кушты. Минемчә, бу барлык һөнәрләрнең абруен күтәрәчәк.

Быел республикада «Профессионаллар» чемпионатында 6000нән артык яшь белгеч катнашачак.

– Бу – безнең өчен абсолют рекорд. Быел конкурста үз көллиятләре, техникумнарында сайлап алынган 2200 кеше катнашачак. Алар иң яхшы яшь белгеч, үз юнәлешендә профессионал дип аталу һәм киләсе этапларда республика исеменнән чыгыш ясау хокукы өчен ярышачак, – ди «Профессиональ компетенцияләр үсеше үзәге» генераль директоры Эмиль Гобәйдуллин.

Аның сүзләренә караганда, чемпионатта катнашучылар – техникум һәм көллият студентлары (шул исәптән читтән торып укучылар). Икенче категория – юниорлар, 14 яшьтән алып мәктәп укучылары. Шулай ук ярышларга 1800 эксперт һәм 900гә якын волонтер җәлеп ителәчәк.

– «WorldSkills» чемпионатыннан аермалы буларак, безнең яшь буенча чикләүләр юк. Урта һөнәри белем алучы һәр кеше катнаша ала, – диде ул.

302 юнәлеш буенча ярышлар 22 шәһәр һәм авылның 87 мәйданчыгында март ахырына кадәр уза. Апрельдә исә югары технологияләр чемпионатының төбәк этабы башлана.

– Чемпионат хәрәкәте елдан-ел үсә. Ел саен компетенцияләрне актуальләштерәбез. Быел 11 яңа юнәлеш өстәдек. Республика предприятиеләре һәм оешмалары белән үзара мөнәсәбәтләр төзүгә аерым басым ясыйбыз. Һәр катнашучыны стажировкага, эшкә урнаштыру – безнең төп бурычларның берсе. Чемпионатта тәкъдим ителгән компетенцияләрнең күпчелеге сәнәгать һәм оборона комплексына бәйле. Монда катнашу республика яшьләренә бу предприятиеләрдә югары хезмәт хакы түләнә торган эш табарга мөмкинлек бирә, – диде Эмиль Гобәйдуллин.

Металл белән слесарьлык эше буенча баш эксперт Рамазан Әүхәдиев фикеренчә, чемпионатта катнашу өчен яхшы белгеч булу гына аз.

– Ярышларга психологик яктан да әзерләнергә кирәк. Остазлар эше мөһим. Алар эшнең нечкәлекләрен сөйләүдән тыш, үзләренең һөнәри сыйфатлары, тәҗрибәләре белән дә уртаклаша. Ярышлар бик киеренке. Барысына да игътибар итәргә кирәк, – диде Рамазан Әүхәдиев.

Ләйсән САФИНА

«ПРОФЕССИОНАЛЛАР» ЧЕМПИОНАТЫ ФИНАЛИСТЛАРЫНА КАРАЛГАН ПРЕМИЯЛӘР

Төбәк дәрәҗәсендә
Алтын медаль ияләре – 150 мең сум, көмеш медаль ияләре – 125, бронза медальгә лаек булганнар 100 мең сум акча белән бүләкләнәчәк.

Федераль дәрәҗәдә
Беренче урын – 300 мең сум, икенче урын – 200 мең һәм өченче урын ияләре 100 мең сум алачак.

Уйлы күңел уйлана

КАПКА ТӨБЕН КӨРИ БЕЛӘСЕҢМЕ?

Синең игътибар иткәнең бармы? Авыл кешесе хәзер капка төбен дә элекке кебек матур итеп көри белми бит, – дип аптырашта калдырды беркөн танышым. – Элек бөтен кеше зур итеп, иркен итеп капка төбен көри, ике якка өелгән көртне тигезләп, кистереп матур итеп калдыра, әле аннары ялт иттереп себереп тә куя иде. Ә хәзер... Кемдер юл гына салып куя, кемдер кечкенә капкасына, гаражына керү юлын гына көри... Бер дә матур түгел бит.

Шушы сөйләшү үземне дә гаҗәпләндергән хәлләрне искә төшерде. Күрше авылның бер урамында яшәүчеләр, электән шулай гадәтләнгәнме, капка төбендәге карны юл уртасына гына чыгаралар иде. Җайлы да, тиз дә бит. Тракторлар чистартып кына китә, кар тагын юл уртасына күчә... Шуңа күрә бу урам беркайчан чиста булмый иде. Техника йөри торгач, кар тыгызлана, таптала. Язын көннәр җылыта башлау белән, асфальт өстендә канаулар пәйда була. Җиңел машиналарга йөрергә дә, бер-берсенә юл бирергә дә уңайсыз була иде. Бер чакны кайтып киләм, танышым кар көри. Гадәттәгечә, карны юл уртасына гына ата. Әле генә трактор чистартып киткән юл тагын кар боткасына әйләнә.

– Сездә дә шушы хәлме ул? Әле генә көрәп кергән идем. Менә трактор чистартып киткән, бөтен кар тагын капка төбендә, – ди бу.

Түзмәдем, күптән әйтәсе килгән сүзләремне әйттем:

– Без, сезнең кебек, карны урам уртасына ташламыйбыз бит...

Үпкәләгәндер дип уйламыйм, әмма әйтүнең файдасы булды дип беләм. Берсеннән берсе күреп дигәндәй, хәзер анда да карны үз капка төпләренә – ике якка көриләр. Болай эшләгәч, техникалар чистартып киткәндә дә капка төпләренә кар таудай өелми, юл да асфальтына кадәр күренеп, чиста булып тора.

Үз капка төпләре дигәннән, Балтачта бер шундый үзгә урам бар: анда яшәүчеләр карны... кыш буе каршы якка ташый. Һәркайсы. Үз капка төбенә түгел, каршы яктагы күршесе биләмәсенә. Моны акыл белән кабул итеп булмый. Юкса, каршы якка кадәр көрәп, эттереп газапланганчы, як-якка ату тизрәк тә, кешечә дә булыр иде. Барыбер ул урынга каршы яктагылар шул ук карны чыгара лабаса. Әле шунысы да бар: беркем дә беркемгә үпкәләми. Менә шундый гадәт.

...Танышыма рәхмәт. Кемнәрдер иртән күзен ачуга, кар яумаганмы дип борчылса яки «тагын кар ява инде» дип аһылдаса, шөкер, арабызда әле, аның кебек, кар көрәүдән дә матурлык эзләүче, аны авырсынып түгел, рәхәтлек тоеп, шөкер итеп эшләүчеләр дә бар икән. Үзе капка төбен «элеккечә» көрәмәсә, ул башка урыннардан матурлык эзләмәс, аларга бөтенләй игътибар да итмәс иде. Ә быелгы карга авылдагылар да, каладагылар да битараф түгел. Битараф калырлык булмады, ахры. Гел проблемалар гына күрүчеләр дә, «Җәй көне бу карны сагынырбыз әле», – диючеләр дә күп булды. Барысы да хаклы. Әнә берничә көн салкыннар булуга, «Салкыннары яманрак икән, кар яуса яхшырак», – диештек.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КАРНЫҢ ДА – ҮЗ ХИКМӘТЕ

Ике көн буена яуганнан соң, кар көртләрен күзәтергә дип, урам буйлап киттем. Үземчә һава сулап йөрим инде. Янына килеп җитмичә, йортлар да күренми, юл да бик тар. Машина күренсә, йөгерә-йөгерә берәр капка төбенә кереп басасы.

Шәһәр янындагы бистә булса да, урамыбыз 13 йортлык кына безнең. Аннан кыр-урман башлана. Шуңа күрә машиналар да үзебезнеке генә, кешеләре дә, хәтта эт-мәчеләре дә... Каршыда гына Виталий бабай йорты. Ике ел элек кинәт кенә үлеп китте ул. Без аны гел искә төшерәбез. Аның кебек тырыш кеше тагын бармы икән? Капка төпләрен генә түгел, асфальт юлны да кырып-себереп куяр иде, бахыр. Йорты янындагы кар өеме урамда иң биеге булып, сокланып карап торыр иде. Үзе төзегән шушы матурлыктан ләззәт ала кебек иде ул. Әтисенең эшен дәвам итәргә улының гына әллә ни исе китмәде. Кәефе булганда гына чистарткалап куя. Бу юлы булдыра алмаган. Гараж алды бөтенләй карга күмелгән. Әле ярый ишегаллары өстән ябык, машинасын шунда кертә икән. Кечкенә капка алдын да ачылырлык итеп кенә, соңыннан гына чистартып куйды. И-и, әтисе исән булсамы, күзге кебек ялтырап торыр иде бу урыннар.

Раил күрше, машина ремонтлау белән шөгыльләнгәч, биләмәсен буеннан-буена кардан чистартып, ел саен парковка сыман урын әмәлли иде. Машина күп килә чөнки. Бу юлы карны куярга урын табып бетерә алмагандыр инде. Иң күп дигәндә, ике машина сыярлык кына чистарткан. Кечкенә капка алдын да чистартып торуны кирәк дип тапмаган. Киресенчә, карны шунда өеп куйган. Зур капкадан гына йөрергә булганнар. Хәзер инде аның янына килгән машиналар башка капка төпләрендә урын эзләп мәш килә.

Алар каршындагы Фәридә кызы белән генә яши. Машиналары юк. Шулай булса да, икәүләп капка төпләрен киң итеп ачып, ялт иттереп куялар иде. «Нишләп азапланасыз? Йөрергә тар юл да җитә бит», – дип әйткәнем дә бар. «Килгән-киткән кеше булыр. Үзебезнең капка төбенә туктар», – ди иде күршем. Бу юлы сукмак кына. Димәк... көч җитмәгән. Хәлләрен белеп чыгарга кирәк булыр.

Белми дә йөргәнмен. Машинасыз кешеләр тагын бар икән әле урамда. Алар да кече капкадан сукмак кына салганнар. Яз көне барыбер эреп бетәр әле дигәннәрдер инде. Нәрсә дисәң дә, өлкән яшьтәге кешеләр яши инде бу йортларда. Алар янәшәсендә инвалид бала тәрбияләүче әнинең машинасы да бар, әмма гараж алды ачылмаган. Бу кадәр карны җиңәргә хәле юктыр, мөгаен. Туганнары килепме, бер дә булмаса, ир-атлар җыелышыпмы, булышып алсалар да ярар иде, дип уйлап куйдым.

Дания апа да бураннан зыян күргән, ахры. Күптән түгел генә читтән кайтып, урам башына йорт салып чыкканнар иде алар. Җил уйнаклый инде монда, бөтен яктан ачык. Карны сыртлап-сыртлап өйгән. Дания апа кече капкасын каерып ачкан да, җимерек урындыкны яткырып, яхшылап терәтеп куйган. Юкка гына түгелдер. Капканы ачык калдыру түгел, эчтән бикләми дә ятмыйбыз бит хәзер. Урамга чыгу юлы да – кәҗә сукмагы гына. Бураннан соң чыга алмаганнардыр болар. Ире дә урын өстендә ята дип ишеткән идем. Әле ярый телефон бар, күршеләренә шалтыраткандыр инде. Анда хәлләр әйбәт. Капка төпләрен футбол кыры кебек ачып куйганнар. Андыйлар тагын да бар әле. Бу йортларда инде ир-атлар яши, балалары да кул астына кергән.

Уйланып йөрим шулай. Аралашу да, ярдәмләшү дигәне дә акрынлап кына юкка чыга бара. Күршеләрнең ничек яшәп ятуларын белмибез дә хәтта. Без бәләкәй чакларда төнлә кар яуса, әти-әни: «Һәдия апа, Мансура апа капкаларын, ишекләрен кар каплап китмәдеме икән? Карап кайтыгыз әле», – дип, иртә таңнан чыгарып җибәрер иде. Көрәкне үзебез белән ала барабыз. Ярты урам җыела иде кайчагында. Мәктәпкә киткәнче кар көрәп, тирләп-пешеп бетә идек. Ул вакытта телефон да юк бит. Күршең дә карамаса, ялгыз әбиләр нишләсен?

Югыйсә хәзер дә бик кирәк инде ул хәл белешү дигәннәре. Олыгайган кешеләргә бигрәк тә. Кар көртләренең файдасы миңа да тиде: бата-чума Дания апалар яшәгән йортның ишегалдына таба атладым...

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru



Сораштыру

Һәрбер йөрәк яңарта

Бусагада – Гашыйклар көне. 14 февральдә билгеләп үтелә торган бу көн – җан сөйгәннәргә тагын бер мәртәбә «яратам» дип әйтер, кайгыртуыңны, җылыңны бүләк итәр өчен сәбәп. Февральнең бу көнендә бер-береңә бүләк бирү, хис аңлату гадәткә кергән. Кемнәр бу көнгә аерым игътибар бирә, ә кемнәр яраткан кешеңне куандыру өчен сәбәп чыкканын көтми? Шуны белештек.

«Яратмыйм» дигәне юк»

Зөлфия ШӘМСУАРОВА, «Манзара» тапшыруы алып баручысы, Камал театрында диктор-тәрҗемәче:
– Гашыйклар көне икәнен күңелдән истә тотсак та, билгеләп үтмибез. Алай да, ирем Раил белән (Камал театры артисты. – **Авт.**) чөкердәшеп, тәм-томнар белән чәйләп алу мәслихәт!

Без бер-беребезне күз карашыннан аңлыйбыз. Яратмыйм дип әйткәне юк, димәк, ярата! Берәр нәрсә үзгәрсә, хәбәр итәр иде. Эш-гамәлләребез белән мәхәббәт аңлатабыз. Ниятләребез белән бер-беребезгә кирәк булуыбызны күрсәтәбез.

14 февральдә без ике спектакль уйныйбыз. Хәзерге вакытта театр, гаиләбез белән гастрольдә әле.

«Яратам да инде яратуыңны» дип үбәм»

Рәдифә НОГМАНОВА, 5 бала анасы, журналист:
– Бу бәйрәмне билгеләү юк бездә. Студент чакта, кыз чакта нидер маташа идек кебек инде. Акыл керә башлагач, кызыгы бетте диимме соң? Безнең бәйрәм түгел бит ул. Безнең милләткә дә, дингә дә хас әйбер түгел дип саныйм. Әгәр дә инде бу кем өчендер мәхәббәттә аңлашуга сәбәп икән – рәхим итсеннәр, каршы килмим.

Гаиләдә «яратам» дип яшәү яшеннән узып барабыз кебек. Шулай да, күңел тулып ташыган чакта әйтәбез бу сүзне. Мин арып кайтканда ирем өйдәге мин эшли торган берәр эшемне эшләп куйса, йә иртән торып ашыккан вакытта машинамны җылытып, кардан чистартып торса: «И-и, яратам да инде мине яратуыңны!» – дип үбеп куям. Ул да шулайрак инде. Еш кына кечкенә балаларыбыз, без кочаклашып торганын күреп: «Муж жену целовать должен!» – дип үбештерәләр дә! Андый чакта: «Әйе шул, әтиегез – мине, мин әтиегезне яратам», – диешеп куябыз. Мәхәббәт ул – гамәл, бер-береңә ышану, бер юнәлешкә карап хәрәкәт итү.

«Кайчак дәшми калу хәерле»

Рифат СӘЛАХ, шагыйрь:
– Минемчә, мәхәббәт аңлату өчен аерым көн яхшы әйбер түгел. Хәләл җефетеңә мәхәббәтеңне һәр көнне аңлатып торырга кирәк. Аерым көн булу, бәлки, бер яктан, никахта булганнар өчен әйбәттер. Ә менә үз тиңен таба алмаган яки югалткан кешеләр нишләсен? Аларга тагын бер кат бу турыда исләренә төшереп, йөрәкләрен телгәләү бик үк яхшы нәрсә түгел шикелле тоела.

Ә мәктәп балалары исә бу әйберне башкача аңлаячак. Аларга, гомумән, андый көнне рөхсәт итү куркыныч. Яшь вакытында ялгыш ясарга этәрү булмасмы бу? Әлеге көннең килеп чыгышына карасак, бу безнең илдә бөтенләй искә алынырга да тиеш түгел.

«Мәхәббәт сүздәме, гамәлдәме?» – дип сорау дөрес. Чөнки кайбер кешеләр эгоист һәм сүздә генә сөйгәннәренә мәхәббәт аңлаткан булалар. Ә кайберәүләрнең гамәлләреннән мәхәббәт сизелеп тора. Минемчә, мәхәббәт сүздә дә, гамәлдә дә булырга тиеш. Ә кайчагында дәшмичә калу тагын да хәерлерәк!

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

САН

Илдә яшәүчеләрнең күпчелеге **(78%)** 14 февральне билгеләп үтәргә җыенмый. SuperJob аналитиклары уздырган сораштыру нәтиҗәләре шуны сөйли. Бу көнгә нидер планлаштырган кешеләр саны **12** процент кына икән. Гашыйклар көненә аерым игътибар бирүчеләр – **34** яшьтән яшьрәкләр **(20%)**.

Ун ир-атның өчесе генә Гашыйклар көнендә сөйгәненә чәчәкләр сатып алачак. Аларның күбесе – шулай ук **34** яшьтән яшьрәкләр **(50%).**

ОПЕРА НИЧЕК ТУА?

tatarstan.ru

Мәдәният дөньясында

Тарихи вакыйга! Бер ел элек – ике яшь-яшь иҗатчы «Кави – Сәрвәр» операсын тәкъдим иткән көнне татар җыр сәнгатенең яңа сәхифәсе язылды. Күптән түгел без шул вакытка кайтып килдек: операның иҗат төркеме аның язылу тарихына багышланган документаль фильм күрсәтте һәм тагын бер кат бу вакыйганың әһәмиятен искә төшерде.

Беренче адымнар

«Кави – Сәрвәр» операсының либретто авторы Айдар Әхмәдиев сөйләгән һәм, беренче карашка, очраклы тоелган вакыйгалар бу операның һичшиксез язылырга тиешлеген раслый кебек.

– Мин «Мергасовский» спектаклендә Сәрвәр Әдһәмованың Кави Нәҗмигә язган хатларын ишеттем. Кайбер өлешләр мине аеруча тетрәндерде. Шуннан бервакыт миңа Мергасов йорты (Кави Нәҗми һәм башка әдипләр яшәгән йорт. – **Авт.**) тирәсен җыештыруда катнашырга туры килде. Ахырдан безнең янга бер ханым килеп, рәхмәтен белдерде һәм китаплар өләште. Кави Нәҗминең оныгы Фәридә Тансык кызы Нәҗметдинова булып чыкты ул. Бүләк иткән китабында исә Кави белән Сәрвәрнең хатлары тупланган иде. Миләүшәгә нәкъ менә шушы тарихка алынырга тәкъдим итүем әнә шул вакыйгаларга бәйле, – дип сөйли Айдар фильмда.

Опера турында уйлана башлаудан алып аны зур сәхнәгә күтәрүгә кадәр дүрт еллап вакыт узган. Ике-өч сәгатьлек «солянка» концерты түгел, югары сәнгать әсәре шул ул. Текст һәм музыка язудан алып акчага бәйле мәсьәләләрне хәл итүгә кадәр күпме көч куелганын яшьләр үзләре генә беләдер. Ләкин «Кави – Сәрвәр»нең композиторы Миләүшә Хәйруллина андый авырлыклар турында артык уйламауларын әйтте.

– Безнең бу тарихны ничек булырга тиеш, шулай итеп һәм бик лаеклы рәвештә күрсәтәсебез килде. Авырлыклар ничектер икенче планга күчте. Башта камера форматында, ягъни берничә артист белән генә куярга уйласак та, архивларда казынып, ул хатларны кат-кат укыганнан соң, мин аның кино-опера булырга тиешлеген аңладым, – дип сөйли ул.

Шулай итеп, «Тарихның әйтеп бетергесез катлаулы чорында өмет һәм мәхәббәтне кайдан табарга?» соравына җавап бирә торган әсәр туган. Тулы бер тарихи чорны сурәтләгән операда катнашкан артистларның санын чамалыйсыздыр. Төп рольләрне исә Артур Исламов (Кави) һәм Эльза Исламова (Сәрвәр) башкарды. Геройларының һәм, гомумән, бу операның тормышларына йогынты ясавын яшерми алар. Хәер, кечкенә генә роле булган артистлар өчен дә зур вакыйга булган ул.

Хәвефле тынычлык

«Кави – Сәрвәр» операсы туу ул – һава җитмәгән чакта кислород битлеге кидертү. Мөгаллим һәм концертмейстер Алсу Барышникова бу вакыйганы әнә шулай бәяли.

– Ни генә дисәк тә, бу вакыйгага тиешле бәяне дистә еллар узгач кына биреп булачак. Без шактый вакыт ниндидер сазлык, тынычлык эчендә яшәдек. Мондый әсәрләр безгә һава кебек кирәк иде. Һәм, ниһаять! – ди ул.

«Кави – Сәрвәр», беренче чиратта, милли опера булуы белән кадерле. Бу җәһәттән аны сәхнәдә куйган режиссер Илгиз Зәйниев Нәҗип Җиһановның бер чыгышын искә ала.

– Мәскәүдә Композиторлар берлегендә милли опера язучы композиторларны каһарманнар дип атый ул. Әйтик, русча опера язсаң, аны әллә ничә театр куя ала. Ә милли опера театры – һәр халыкта берәү. Композитор аңлап яза: я ул шушы бердәнбер театрда куела, я бөтенләй куелмый. Шулкадәр көч куюның мәгънәсе булачакмы, юкмы икәнен алдан белә алмый ул, – ди режиссер.

Илгиз Зәйниев сүзләре белән әйтсәк, без бу эшне системага салмыйча, киләчәкне хәзердән үк уйламыйча, сәнгатебезгә карата зур гөнаһ эшлибез. Миләүшә Хәйруллина кебек: «Мин үз халкымның шушындый операсы булуын, һәм аны зур горурлык белән бөтен дөньяга күрсәтә алуын теләдем», – дип торучылар бик күп түгел. Булганнарын кадерлисе иде...

Лилия ГЫЙМАЗОВА

«Кави – Сәрвәр» операсының премьерасы узган елның февралендә булды. Быел 27–28 апрельдә С. Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залында аны кабатлап куялар.

Фикер

Фәридә НӘҖМЕТДИНОВА, Кави Нәҗми һәм Сәрвәр Әдһәмованың оныгы:
– Әлеге ике иҗатчы минем яныма фатиха сорап килгән вакытта, бераз икеләнгән идем. Чөнки алар миңа артык яшь булып тоелды. Билгеле, без аларга үтенеч-теләкләребезне җиткердек. 1930 нчы елларда булган вакыйгаларны сурәтләү – шактый катлаулы һәм четерекле мәсьәлә. Безнең ул чорда яшәгән кешеләрне көчсезлектә дә, башкасында да гаепләргә хакыбыз юк. Операны карагач, «Ничек сез Кави Нәҗмине шулкадәр мескен итеп күрсәтергә ирек бирдегез?» – диюче дә булды. Ләкин алар бит – тере кешеләр! Алар да адәм баласына хас булган хисләрне кичерә...

Гүзәл НӘҖМЕТДИНОВА, Кави Нәҗми һәм Сәрвәр Әдһәмованың оныгы:
– Аларны ак яки кара буяу белән генә ясау мөмкин түгел. Операда геройларның хис-кичерешләрендәге үзгәрешләр гаҗәеп төгәллек белән күрсәтелә. Гомумән, мин мондый әсәр язылачагына ышанмый идем инде. Үз гомеремдә шактый опералар күргән кеше буларак әйтәм: бу – бернигә дә охшамаган, чын мәгънәсендә бөек әсәр!

Хәтер

ШИГЪРИЯТЕ МОҢЛЫ ҖЫР ИДЕ

КАЗАНДА ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВАНЫ ИСКӘ АЛДЫЛАР

Җыр әнисе, шат күңелле, кояшлы шагыйрә, татар әдәбияты, сәнгатенең төрле өлкәләрендә иҗат иткән күпкырлы шәхес.

Күренекле шагыйрә, драматург, күпсанлы популяр җырлар авторы Гөлшат Зәйнашеваны искә алу кичәсендә бу сүзләр күп кабатланды. Концертта ярты гасыр дәвамында шигърият мәйданын тоткан мәшһүр шагыйрәнең һәркемгә таныш, моңлы, күңелгә үтеп керүче җырлары яңгырады. Без исә Гөлшат Зәйнашева турында кайбер истәлекләрне барладык.

«Иҗатының көче – халыкчанлыгында». Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, шагыйрә Илсөяр Иксанова Гөлшат Зәйнашева турында әнә шулай диде.

– Гөлшат Зәйнашева – сөекле шагыйрәбез, татар җыр сәнгатенә зур өлеш керткән, татар әдәбиятында үзенең кабатланмас урынын алган шәхес. Аның иҗатын бер сүз белән генә аңлатып булмый. Гөлшат Зәйнашеваның үзенчәлеге, көче – әлбәттә, халыкчанлыгында. Ул үзенең чордашлары, татар музыка сәнгатенә нигез салган, аны үстергән иң күренекле композиторлар белән эшләгән. Бу – аның зур бәхете. «Туган җирем – Татарстан» җырын (Александр Ключарев музыкасы) Татарстанның гимны дип әйтергә була. Бу – үлемсез җырлар. Аларда гади генә сүзләр, әмма шул гадилек артында нинди тирән мәгънә ята, – ди шагыйрә.

Илсөяр Иксанова Гөлшат Зәйнашевага бәйле бер вакыйганы да искә алды:

– Бер китабымның кереш сүзенә Гөлшат апаның шигыреннән сүзләрне алып, һич тә шикләнмичә, халык җырыннан дип бастырдым. Шуннан Гөлшат апа шалтырата: «Илсөяр, нишләп халык җырыннан дип куйдың, ул бит – минем сүзләр», – ди. Шундый уңайсыз булды. Аның сүзләрен халык җыры белән бутау – бер караганда, шагыйрәгә зур дәрәҗә. Әмма мин Гөлшат ападан гафу үтенеп, төзәтеп куйдым. Аның җырлары безнең күңелләрдә мәңге яши. Гөлшат апаны искә төшереп, аның мирасын җыеп торуга зур хезмәт керткән шәхесләр – аның гаиләсе – кызы (Асия Зәйнашева) һәм кияве (Рафаэль Шакирҗанов). Гөлшат апабызны искә алуыбыз аның рухына дога булып ирешсен иде.

Татарстанның атказанган артисты Айгөл Хәйри шагыйрә белән дуслыгы ничек башлануы турында сөйләде:

– Гөлшат апаның кызы Асия миндә җырга, моңга мәхәббәт уятты. Ул мине профессиональ музыка дөньясына кертеп җибәрде. Гөлшат апа белән дуслыгыбыз балачагымнан ук башланды. Сигез яшемдә 16 нчы балалар музыка мәктәбендә Асия Зәйнашева җитәкчелегендәге хор-дирижерлык классында укый башладым. Ул чакта аның кем кызы булганын белми идем әле. Аннан Асия апа «Айсылу» вокаль ансамблендә Гөлшат Зәйнашеваның сүзләренә язылган җырларны өйрәтә башлады. Шунда мин аның нинди зур шәхеснең кызы икәнен аңладым. Гөлшат Зәйнашева белән аның җырлары аша таныштым. Аның «Минем исемем Айгөл» дигән җыры – минем өчен аннан калган бик кадерле мирас.

«Татар милләтенең үлемсез җырлары авторы». Монысы – Татарстанның халык язучысы Рабит Батулланың Гөлшат Зәйнашевага атап әйтелгән сүзләре.

– Гөлшат Зәйнашева бик бәхетле иҗатчы булды. Киң колачлы иҗатында ул балаларны да онытмый, алар өчен шаян, гыйбрәтле шигырьләр-җырлар язды. Гөлшат апа легендар композиторлар һәм җырчылар белән бер чорда яшәгән, алар белән бергәләп үлмәс җырлар иҗат иткән. Ул моңлы, дәртле җырларны башкарырга язмыш аның юлына атаклы җырчылар Әлфия Авзалова белән Илһам Шакировны чыгарган. Гөлшат Зәйнашеваның йөзләгән җыры бүген дә телдән төшми, җырлана.

Ләйсән САФИНА

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 2061 данә
Гомуми тираж – 11272 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 217

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+